ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

15.11.2022

Казан ш.

**КАРАР**

№ 357-73/кс-2022

«Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 №246-79/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2023 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә, 2023-2025 елларга җайга салынулы оешманың эчә торган суга озак сроклы тарифларына һәм кирәкле тулай табышына төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга эчә торган суга тарифлар билгеләү турында» 20.11.2020 №246-79/кс-2020 карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2021 №420-108/кс-2021 карары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карар белән төзәтелгән 2023 елга тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 №246-79/кс-2020 карарының 1 нче кушымтасына үзгәреш кертү турында һәм «Восток – Энерго» җитештерү-коммерция фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчә торган суга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 №246-79/кс-2020 карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 01.12.2021 №420-108/кс-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2020 №246-79/кс-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 357-73/кс-2022 карары редакциясендә) 1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Восток - Энерго» ЖКФ» ЖЧЖ өчен эчәргә яраклы суга 2021-2025 елларга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Чистай муниципаль районы | | |
| 1 | «Восток - Энерго» ЖКФ» ЖЧЖ | | |
| 1.1 | башка кулланучылар (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 22,45 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 23,00 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 23,00 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 23,80 |
| | | 01.01.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 24,81 |
| | | 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 30 июненә кадәр | 24,81 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 27,28 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 27,01 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 27,01 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге